ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 00972F37E36420D8354157DE4BEA6BFFFC
Владелец: Валиева Венера Марсовна
Действителен с 26.10.2022 до 19.01.2024

Татарстан Республикасы
“Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге
“Куакбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе”
муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе

Педагогик киңәшмә
утырышында кабул ителде
Беркетмә №______
«____» __________2023 ел

Раслыйм
Приказ №____
«____» ___________2023 ел
Директор: В.М. Вәлиева

**Социаль – гуманитар юнәлештәге**
**өстәмә гомуми белем бирү программасы**

# «Туган тел»

**Укучыларның яше – 12-13 яшь**
**Гамәлгә ашыру вакыты – 1 ел**

**Төзүче автор:**
**өстәмә белем бирү педагогы**
__________________________________

**Куакбаш авылы**

**2023-2024 нче уку елы**



Документ создан в электронной форме. № 100 от 31.08.2023. Исполнитель: Валиева В.М.
Страница 1 из 11. Страница создана: 28.10.2023 10:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Документ создан в электронной форме. № 100 от 31.08.2023. Исполнитель: Валиева В.М.
Страница 2 из 11. Страница создана: 28.10.2023 10:01

## Аңлатма язуы

Эш программасы түбәндәге норматив-хокук документларына нигезләнеп төзелде:
- Конвенция о правах ребенка
- Конституция Российской Федерации (статьи 9,36,42,58,71,72,114)
- Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации»
- Санитарно-эпидемиологические правила и нормативы СанПиН 2.4.4.3172-14
- Концепция развития дополнительного образования детей (от 04.09.2014)
- Стратегия развития воспитания в Российской Федерации на период до 2025 года
- Указ Президента Российской Федерации от 29 мая 2017 года № 240 "Об объявлении в Российской Федерации Десятилетия детства"
- Приказ МО и Н РФ от 29.08.2013г № 1008 «Об утверждении порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам»
- Закон Республики Татарстан № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года «Об образовании»
- Постановление КБ РТ от 12 октября2011 №846 «О внесении изменений в отдельные постановления КБ РТ»
- Приказ МО и Н РТ № 1465/14 от 20 марта 2014 года «Об утверждении Модельного стандарта качества муниципальной услуги по организации предоставления дополнительного образования детей в многопрофильных организациях дополнительного образования»
- “Татарстан Республикасының дәүләт телләре турында” Законы (Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. от 03.03.2012г.) “О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан”)
- Устав МБОУ «Куакбашская ООШ»
- Положение о разработке дополнительных общеобразовательных программ в МБОУ «Куакбашская ООШ»

## Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше

**Юнәлеше –социаль-гуманитар**

“Туган тел”программасы дәресләр рамкасында гына чикләнми, балаларның мөстәкыйль иҗатын үстерү максатын тормышка ашыра. Программаны тормышка ашыруның төп принцибы – тәрбия-белем эшчәнлеген дифференцияләштерү. Программа һәр тәрбияләнүченең индивидуаль үзенчәлекләрен, мөмкинчелекләрен һәм сәләтен исәпкә ала.

**Актуальлеге.** Татар халкының милли-мәдәни кыйммәтләренең берсе - татар теле. Шәхеснең интеллектуаль, иҗади сәләтләрен һәм әхлак сыйфатларын үстерүдә туган телнең роле бик зур. Шуңа күрә мәктәптә белем алу процессында ана теленең әһәмиятен аңлау бик кирәк.

Татар теленең эстетик кыйммәтен аңлау, туган телгә карата хөрмәт, аның белән горурлану булырга тиеш. Милли мәдәният күренеше буларак татар теленең чисталыгын саклау ихтыяҗы бик зур. Сөйләм культурасында үзүсешкә омтылу булырга тиеш.

Сөйләшү процессында фикер һәм хисләрне иркен белдерү өчен сүзлек запасының һәм үзләштерелгән грамматик чараларның җитәрлек күләмдә булуы кирәк.

**Программаның яңалыгы:**

Укыту-тәрбия эшчәнлеге төрле эш юнәлешләре аша тормышка ашырыла:
-тыңлаучы культурасы нигезләре тәрбияләү;
-башкаручы эшчәнлеге күнекмәләре тәрбияләү;



Документ создан в электронной форме. № 100 от 31.08.2023. Исполнитель: Валиева В.М.
Страница 3 из 11. Страница создана: 28.10.2023 10:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

-тел белеме буенча белемнәр туплау.

Бу эш юнәлешләре үзара үреләләр, бер-берсен тулыландыралар, нәтиҗәдә, тәрбияләнүченең әхлак сыйфатларын тәрбиялиләр.

**Педагогик максатчанлыгы.**

Укыту-тәрбия процессы 3 төрле эшчәнлекне үз эченә ала:

-теоретик белемнәр бирү

- мөстәкыйль эш

-алган белемнәрне практикада куллану

Алган белемнәр ярдәмендә балалар чагыштырырга, анализларга, планлаштырырга, эчке максатлар куярга, бу максатларга омтылырга өйрәнәләр.

**Төп максат:**

- укучыларның татар теленең фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрне системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү;
- телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү ;
- укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилли белергә күнектерү;
- татар әдәби тел нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга, аларны тиешенчә куллана белергә өйрәтү;
-телнең милли мәдәниятнең чагылышы булуын, тел һәм тарих бердәмлеген аңлату, татар теленең милли-мәдәни үзенчәлекләренә төшендерү; татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү;
- телнет улы бер система буларак күзаллау;
- текст һәм башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны таба белү һәм аны тиешенчәү згәртә алу күнекмәләрен үстерү;
- укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын камилләштерү.

**Бурычлар:**

1. Теоретик белемне тирәнтен өйрәнү һәм системалаштыру;
2.Укучыларның игътибарын телнең эстетик функциясен чагылдыручы әдәби текстка, өйрәнелә торган тел күренешләренең сәнгатьлелек ягына юнәлтү;

-аның белән эшләгәндә балалар туган телнең матурлыгын күрергә һәм ишетергә өйрәнсеннәр, нинди сурәтләү чаралары аша аның тормышка ашырылуын аңласыннар өчен телнең тасвирлау һәм сурәт ясау мөмкинлекләрен күрсәтү, телнең җанлы халәтен, кулланылыш рәвешен өйрәнеп, сүз белән сөйләм арасындагы бәйләнешнең нигезенә ныграк төшенергә, әдәби әсәрдә һәм автор сөйләмендә сүзнең тәмен, ямен, матурлыгын тоярга, үз сүзен, фикерен әйтә белергә өйрәтү.

**Программаның аерымлык үзенчәлеге.**

Программа түбәндәге принципларга нигезләнеп төзелде:

- кыйммәти-мәгънәви тигезлек (педагог белән укучының максаты уртак)
- яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу;
- креативлык

Программа үтәлешендә катнашучы балаларның яше – 12-13 яшь.

Үтәлү вакыты – 1 ел.

Шөгыльләрне үткәрү режимы:

атнага 1сәгать, 1 елга 34 сәгать.

Уку процессын планлаштырганда, түбәндәге эш **формалары** күздә тотыла:

1. Фронталь эш.
2. Индивидуаль эш.



Документ создан в электронной форме. № 100 от 31.08.2023. Исполнитель: Валиева В.М.
Страница 4 из 11. Страница создана: 28.10.2023 10:01

3. Төркемнәрдә эш.
4. Парларда эш.

**Программа үтәлешеннән соң көтеләчәк нәтиҗәләр:**

-сүзләрне әдәби тел нормаларына нигезләнеп әйтү;
орфографик принип үзенчәлекләрен белү; шуларга нигезләнеп, сүзләрне дөрес язу, бигрәк тә кушма, ясалма, парлы, тезмә һәм кыскартылма сүзләрнең дөрес язылышын аңлата алу; төрле сүзлекләрдән, беренче чиратта орфографик сүзлектән, кирәгенчә файдалана белү; үзеңнең һәм башкаларның хаталарын төзәтү күнекмәләренә ия булу;
-сүзлек составындагы татар теленең үз сүзләрен, башка телләрдән кергән алынма сүзләрне, төрле тармакка караган сүзләрне аера белү, алардан урынлы файдалану; синоним, антоним һәм омонимнарның үзенчәлекләрен белү; аңлатмалы сүзлек; фразеология һәм синонимнар, шулай ук башка төр сүзлекләрдән нәтиҗәле файдалану; укучының үз сөйләмен һәм чит кеше сөйләгәнне сүз һәм фразеологик берәмлекләрнең төгәл, стилистик яктан урынлы кулланылуы ягыннан бәяли алу;
-сүзнең мәгънәле кисәкләре; мәгънәле кисәкләрнең төп билгеләрен, тамыр һәм нигез сүзләрне, шулай ук кушымчаларны һәм аларның функцияләре буенча төрләрен аера белү; сүзләрне мәгънәле кисәкләргә таркатa белү күнекмәләренә ия булу;
-сүз ясалышы төрләрен белү; сүз ясалышы белән форма ясалышы арасында аерманы аңлату;
-сүзләрне төркемләү принципларын аңлата алу; һәр сүз төркеменең төп билгеләрен, төрләнешен, төркемчәләрен аера белү; сүзләргә морфологик һәм морфологик-синтаксик анализ ясау күнекмәләренә ия булу; сөйләмдә сүз төркемнәрен дөрес һәм урынлы куллану;
-синтаксисның нәрсәгә өйрәтүен, сөйләм берәмлекләрен белү; сөйләмдә сүзләр бәйләнешен һәм аларны формалаштыру чаралары үзләштерү; сүзтезмә һәм җөмлә билгеләрен белү һәм аларны мисаллар белән дәлилли алу; гади һәм кушма җөмләләрне бер-берсеннән аера белү; әйтелү максатыннан чыгып, җөмлә төрләрен (хикәя, сорау, боерык җөмләләрне), шулай ук тойгылы җөмләне белү, аларны дөрес интонация белән укый (әйтә) алу; җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен, аерымланган иярчен кисәкләрне, тиңдәш кисәкләрне, эндәш сүзләрне һәм кереш сүзләрне тану, аларга хас үзенчәлекләрне мисаллар өстендә аңлата алу; тезмә кушма җөмләләрнең төрләрен, иярченле кушма җөмләләрнең төзелеше һәм мәгънәсе ягыннан төрләрен, аларга хас бәйләүче чараларны аңлату; кушма җөмләләрнең компонентлары арасында тыныш билгеләрен дөрес кую, җөмләләрне дөрес интонация белән уку (әйтү) күнекмәләренә ия булу, катлаулы төзелмәләрне һәм теземне гамәли рәвештә үзләштерү һәм дөрес интонация белән укый белү; туры һәм кыек сөйләмгә хас интонация һәм тыныш билгеләрен үзләштерү; җөмләләрне төзелеше һәм мәгънәсе ягыннан аера алу; җөмләләргә тулы синтаксик анализ ясый белү;
-тыныш билгеләренең мәгънә ачыклыгы өчен бик кирәкле чара булуына төшенү һәм шуны мисаллар өстендә аңлата алу; җөмлә ахырында, кушма җөмлә, катлаулы төзелмә өлешләре арасында тыныш билгеләрен дөрес кую һәм шуларга аңлатма бирә алу; җөмлә кисәкләре арасында (ия һәм хәбәр арасында – сызык), җөмләнең аерымланган кисәкләре (аныклагыч һәм хәлләр), модаль кисәкләр (эндәш сүзләр, кереш сүз һәм кереш җөмләләр), тиңдәш кисәкләр; ымлык һәм аваз ияртемнәре, шулай ук *әйе һәм юк* сүзләре янындатиешле тыныш билгеләрен дөрес кую; куштырнакларның куелу очракларын (диалог формасындагы язылмаган туры сөйләмне аеру; китап, газета, журнал һәм төрле оешма исемнәрен белдерү, я гадәти мәгънәсеннән башкачарак мәгънә белдергән сүзләрне сиземләтү өчен) гамәли рәвештә куллана белү; шулай ук күп нотаның ролен (текст яки абзац башында – дәвамы булуын, текст эчендә – төшереп калдырылган сүз яки җөмлә



Документ создан в электронной форме. № 100 от 31.08.2023. Исполнитель: Валиева В.М.
Страница 5 из 11. Страница создана: 28.10.2023 10:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

булуын, текст азагында сөйләмнең әйтелеп бетмәвен күрсәтү өчен) аңлау; шартлы рәвештә тыныш билгесе буларак карала торган “кызыл юл”ның ролен аңлата алу;
-шулай ук әдәби әсәрнең жанрын тану (әдәбияттан алган мәгълүматлар күз алдында тотыла), әсәрнең төп идеясен аңлау, тексттагы проблемаларны формалаштыру, текстта күтәрелгән проблемаларны үз дәлилләрен китереп аңлата белү;
-изложение һәм сочинениеләрне, сөйләм төрләренә туры китереп, төрле жанрда язу.
-Язмаларны сыйфатлама, модальлек, эмоциональлек элементларын, стиль үзенчәлекләрен кулланып тулыландыру һәм шомарту;
-әсәр яки аның бер өлеше нигезендә конспект төзү, тезислар әзерләү, кемгә дә булса характеристика язу;
-эш кәгазьләреннән хат, белешмә, мәкалә, расписка, акт, гариза һәм беркетмәләрне мөстәкыйль рәвештә яза алу.

**Контроль төрләре һәм формалары.**
Программаның үзләштерелүе укучылар тарафыннан кроссвордлар төзү, тестлар эшләү, практик эшләр формасында даими контрольдә тотыла.
Программа үтәлеше нәтиҗәләре инша һәм төрле характердагы эш кәгазьләре язу формасында күрсәтелә.

**Тематик планлаштыру.**

| № | Бүлекләр һәм темалар | Сәгатьләр саны | | | | Контроль формалары |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теоретик бүлек | Гамәли бүлек | Тестлар буенча тикшерү эшләре | |
| 1 | **Фонетика.** Хәрефләр һәм авазлар. Сүзгә фонетик анализ ясау. Текст белән эш. | 3 | 1 | 1 | 1 | Мини- тест. Перфокарталар белән эш. |
| 2 | **Орфография.** Татар теле орфографиясенең кыен очраклары. Орфографик белемнәрне тикшерү өчен тестлар эшләү. | 3 | 1 | 1 | 1 | Сүзлек белән эш, дидактик материаллар ясау. Туган як темасына кроссвордлар ясау. Тестлар. |
| 3 | **Графика.** Татар хакында язу тарихы. | 2 | 1 | 1 | | Туган тел темасына докладлар сөйләргә әзерләнү. |
| 4 | **Лексикология.** Семасиология. Татар теленең сүзлек составы. Фразеология. Текст белән эш. | 3 | 1 | 2 | | Проект белән эш. Кроссвордлар ясау. Тестлар. |



Документ создан в электронной форме. № 100 от 31.08.2023. Исполнитель: Валиева В.М.
Страница 6 из 11. Страница создана: 28.10.2023 10:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | **Сүз ясалышы.** Сүз ясалышы буенча тестлар эшләү. | 3 | 1 | 1 | 1 | Практик эш. Тестлар. |
| 6 | **Морфология.** Мөстәкыйль мәгънәле сүз төркемнәре, ярдәмче сүз төркемнәре. Сүзләргә морфологик анализ ясау. | 4 | 3 | 1 | | Практик эш. Таблицалар ясау. |
| 7 | **Гади җөмлә синтаксисы.** Алар янында тыныш билгеләре. Җөмләдә тел-сурәтләү чаралары. Текст өстендә эш. | 2 | 1 | 1 | | Әдәби текст белән эш. Тестлар. |
| 8 | **Кушма җөмлә.** Кушма җөмләдә тыныш билгеләре. Җөмләгә синтаксик анализ ясау. Тестлар эшләү. | 4 | 2 | 1 | 1 | Проект яклау.<br>Практик эш. Тестлар. |
| 9 | **Текст.**Текст – сөйләмнең бөтен үзенчәлекләрен үзендә туплаган сөйләм берәмлеге. Грамматик һәм синтаксик нормалар. Бирелгән текст буенча инша язып карау. | 4 | 2 | 2 | | Туган якка, андагы күренекле шәхесләргә карата текстлар буенча инша язу. |
| 10 | **Стилистика һәм сөйләм культурасы.** | 3 | 1 | 2 | | Сүзлек белән эш. |
| 11 | **Тел турында гомуми мәгълүмат.** | 2 | 1 | 1 | | Тел турында инша язу. |
| 12 | Татар теленнән тест эшләре. | 2 | | | 2 | Практик эш. Тестлар. |

**Укыту программасының эчтәлеге.**

1. **Фонетика.** Хәрефләр һәм авазлар. Сүзгә фонетик анализ ясау. Текст белән эш.

2. **Орфография.** Татар теле орфографиясенең кыен очраклары. Орфографик белемнәрне тикшерү өчен тестлар эшләү.

3. **Графика.** Татар хакында язу тарихы.



Документ создан в электронной форме. № 100 от 31.08.2023. Исполнитель: Валиева В.М.
Страница 7 из 11. Страница создана: 28.10.2023 10:01

4. **Лексикология.** Семасиология. Татар теленең сүзлек составы. Фразеология. Текст белән эш.

5. **Сүз ясалышы.** Сүз ясалышы буенча тестлар эшләү.

6. **Морфология.** Мөстәкыйль мәгънәле сүз төркемнәре, ярдәмче сүз төркемнәре. Сүзләргә морфологик анализ ясау.

7. **Гади җөмлә синтаксисы.** Алар янында тыныш билгеләре. Җөмләдә тел-сурәтләү чаралары. Текст өстендә эш.

8. **Кушма җөмлә.** Кушма җөмләдә тыныш билгеләре. Җөмләгә синтаксик анализ ясау. Тестлар эшләү.

9. **Текст.**Текст – сөйләмнең бөтен үзенчәлекләрен үзендә туплаган сөйләм берәмлеге. Грамматик һәм синтаксик нормалар.Бирелгән текст буенча инша язып карау

10. **Стилистика һәм сөйләм культурасы.**

11. **Тел турында гомуми мәгълүмат.**

12. Татар теленнән тест эшләре.

## Календарь-тематик план

| № | Шөгыль темасы | Сәгать саны | Шөгыльне оештыру формалары, төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт |
| 1 | **Фонетика.** Хәрефләр һәм авазлар. | 1 | Мини- тест | 6.09. | |
| 2 | Сүзгә фонетик анализ ясау. | 1 | Практик эш | 13.09 | |
| 3 | Текст белән эш. | 1 | Перфокарталар белән эш | 20.09 | |
| 4 | **Орфография.** | 1 | Сүзлек белән эш, дидактик материаллар ясау | 27.09 | |
| 5 | Татар теле орфографиясенең кыен очраклары. | 1 | Туган як темасына кроссвордлар ясау | 4.10 | |
| 6 | Орфографик белемнәрне тикшерү өчен тестлар эшләү. | 1 | Тестлар | 11.10 | |
| 7 | **Графика.** | 1 | Туган тел темасына докладлар сөйләргә әзерләнү | 18.10. | |
| 8 | Татар халкында язу тарихы. | 1 | Туган тел темасына докладлар сөйләргә әзерләнү | 25.10 | |
| 9 | **Лексикология.** Семасиология. Фразеология. | 1 | Проект белән эш | 8.11 | |
| 10 | Татар теленең сүзлек составы. | 1 | Кроссвордлар ясау | 15.11 | |
| 11 | Текст белән эш. | 1 | Тестлар | 22.11 | |



Документ создан в электронной форме. № 100 от 31.08.2023. Исполнитель: Валиева В.М.
Страница 8 из 11. Страница создана: 28.10.2023 10:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 12 | **Сүз ясалышы.** | 1 | Практик эш | 29.11. | |
| 13 | Сүз ясалыш ысуллары. | 1 | Практик эш | 6.12 | |
| 14 | Сүз ясалышы буенча тестлар эшләү. | 1 | Тестлар | 13.12 | |
| 15 | **Морфология.** | 1 | Чыгышлар | 20.12 | |
| 16 | Мөстәкыйль мәгънәле сүз төркемнәре. | 1 | Таблицалар ясау | 27.12 | |
| 17 | Ярдәмче сүз төркемнәре. | 1 | Таблицалар ясау | 10.01 | |
| 18 | Сүзләргә морфологик анализ ясау. | 1 | Практик эш | 17.01 | |
| 19 | **Гади җөмлә синтаксисы.** Алар янында тыныш билгеләре. | 1 | Тестлар | 24.01 | |
| 20 | Җөмләдә тел-сурәтләү чаралары. Текст өстендә эш. | 1 | Әдәби текст белән эш | 31.01 | |
| 21 | **Кушма җөмлә.** | 1 | Проект яклау | 7.02 | |
| 22 | Кушма җөмләдә тыныш билгеләре. | 1 | Проект яклау | 14.02 | |
| 23 | Җөмләгә синтаксик анализ ясау. | 1 | Практик эш | 21.02 | |
| 24 | Тестлар эшләү. | 1 | Тестлар | 28.02 | |
| 25 | **Текст** – сөйләмнең бөтен үзенчәлекләрен үзендә туплаган сөйләм берәмлеге. | 1 | Чыгышлар | 6.03. | |
| 26 | Грамматик һәм синтаксик нормалар. | 1 | Практик эш | 13.03 | |
| 27 | Бирелгән текст буенча инша язып карау. | 1 | Туган якка, андагы күренекле шәхесләргә карата текстлар буенча инша язу | 20.03 | |
| 28 | Бирелгән текст буенча инша язып карау. | 1 | Туган якка, андагы күренекле шәхесләргә карата текстлар буенча инша язу | 3.04 | |
| 29 | **Стилистика һәм сөйләм культурасы.** | 1 | Сүзлек белән эш | 10.04. | |
| 30 | Стилистика һәм | 1 | Практик эш | 17.04 | |



Документ создан в электронной форме. № 100 от 31.08.2023. Исполнитель: Валиева В.М.
Страница 9 из 11. Страница создана: 28.10.2023 10:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | сөйләм культурасы. | | | | |
| 31 | Стилистика һәм сөйләм культурасы. | 1 | Практик эш | 24.04 | |
| 32 | **Тел турында гомуми мәгълүмат.** | 1 | Тел турында инша язу | 8.05 | |
| 33 | Тел турында гомуми мәгълүмат. | 1 | Тел турында инша язу | 15.05 | |
| 34 | Татар теленнән тест эшләре. | 1 | Практик эш | 22.05 | |

**Укыту-методик комплект**

- Сафиуллина Ф.С, Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Урта һәм югары уку йортлары өчен дәреслек, Казан, «Мәгариф», 2002.

**Материаль – техник тәэмин ителеш.**

-Санитар-эпидемиологик кагыйдә һәм таләпләргә (СанПиН 2.4.2 № 178-02) җавап бирүче кабинет

- методик фонд (белешмәләр, энциклопедияләр, сүзлекләр h.б. әдәбият)

-ноутбук

**Әдәбият**


1. Вагыйзов С.Г. Кызыклы грамматика. Укытучылар өчен кулланма Казан, «Мәгариф», 2002.
2. Вәлиева Ф.С, Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. Казан, «Раннур», 2002.
3. Диктантлар җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлары өчен. Укытучылар өчен кулланма. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2006;
4. Максимов .Н. В. Татар теленнән тестлар. Уку-укыту ярдәмлеге. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2008;
5. Сафиуллина Ф.С, Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Урта һәм югары уку йортлары өчен дәреслек, Казан, «Мәгариф», 2002.
6. Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа:5-11 нче сыйныфлар.-Казан: Мәгариф, 2010.
7. Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары. 5-11 нче сыйныфлар. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2010.

-Интернет-ресурсы:

**http://knigi.link/vneuchebnaya-deyatelnost_1413/osnovnyie-tsennosti-funktsii-dopolnitelnogo-51901.html**Основные ценности и функции дополнительного образования

https://www.tspu.edu.ru/files/ped_news/методика обучения и воспитания в системе дополнительного образования детей

http://elib.gnpbu.ru/text/vozrastnaya-pedagogicheskaya-psihologiya_petrovskogo_1979/fs,1/ Возрастная и педагогическая психология




Документ создан в электронной форме. № 100 от 31.08.2023. Исполнитель: Валиева В.М.
Страница 10 из 11. Страница создана: 28.10.2023 10:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 100 от 31.08.2023
Инициатор согласования: Валиева В.М. Директор
Согласование инициировано: 28.10.2023 10:01

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Валиева В.М. | | Подписано 28.10.2023 - 10:02 | - |